АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2017 елның 24 июле № 14 нче номер

**Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә
бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар
белән идарә итәргә,
яисә идарәнең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү тәртибе**

79-ФЗ номеры белән 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән «Россия Федерациясенең гражданлык хезмәте турындагы» Федераль законның 1 маддәсенең 3 пунктына нигезләнеп,

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә, яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирә торган күрсәтелгән тәртипне (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз вәкаләтемдә калдырам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

**Татарстан**
**Республикасы**
**Инвестицон үсеш агентлыгы**
**боерыгы буенча**
**2017 елның 24 июлендә**
**14нче номер астында расланган**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә,
яисә идарәнең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү

ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә, яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) 2004 елның 27 июлендә 79-ФЗ "Россия Федерациясендә гражданлык хезмәте турында" Федераль законының 17 маддәсенең 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Агентлык) аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында түләүсез нигездә иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, дача куллану кооперативы, күчемсез шәхси милек ияләре ширкәте (алга таба – коммерцияле булмаган оешма) идарә коллегиаль ораганнарында катнашуның рөхсәт ителү процедурасын регламентлый. Федераль закон тарафыннан каралган, йә булмаса Россия Федерациясе закончалыгы буенча дәүләт органы исеменнән башкарыла торган очрак булмаганда, әлбәттә.

Әлеге Тәртип аны яллаучының вәкиле буларак Агентлык җитәкчесе (алга таба – җитәкче) күздә тотылган Татарстан Республикасының Агентлыктагы барлык граждан хезмәткәрләренә дә кагыла.

2. Түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә, яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт сорап гариза тапшыру (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре

тарафыннан әлеге Тәртипкә 1нче номерлы Кушымта буенча кулдан язылып тапшырыла.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны Коррупция һәм башка төр хокук бозуларны кисәтү буенча эш алып баручы җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат гаризаны, ул килеп кергән көнне үк, әлеге Тәртипкә 2нче номерлы Кушымта нигезендәге тиешле форма буенча терки.

5. Җаваплы зат Гаризаның алдан каралышын башкара һәм аның нәтиҗәләре буенча йомгак әзерли.

Гаризаны алдан караган вакытта Җаваплы зат Гариза тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итү планы буенча аның вазыйфаларына нәрсә керүен ачыклый торган аңлатмалар белән документлар таләп итәргә хокуклы.

Йомгак нәтиҗә граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә, яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт ителү-ителмәү хакындагы тәкъдимне үз эченә алырга тиеш.

6. Гариза теркәлгәннән соң, 5 эш көненнән дә арттырмыйча, Җаваплы зат Гаризаны, Йомгакның кушымтасы һәм башка документлар (булган очракта) белән бергә, түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә, яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт сораучы граждан хезмәткәренең үтенече буенча карар кабул итәр өчен җитәкчегә (яисә аның вазыйфасын башкаручыга) тапшыра.

Җитәкче (яисә аның вазыйфасын башкаручы) Гариза алынганнан соң 2 эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Җаваплы зат җитәкче (яисә аның вазыйфасын башкаручы) карар кабул иткәннән соң 2 эш көн дәвамында граждан хезмәткәренә аның Гаризасы буенча нәтиҗәне хәбәр итә һәм аңа җитәкче резолюциясе белән бергә юридик бүлек мөһере белән расланган Гариза нөсхәсен тапшыра. Гаризаның төп нөсхәсе исә, җитәкче резолюциясе белән бергә, граждан хезмәткәренең шәхси эшенә беркетелә.

Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны
тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар
белән идарә итәргә, яисә
идарәнең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү Тәртибенә

**1нче Кушымта**

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгы
җитәкчесенә
____________________________
___________________________________
(Ф.И.О., билгеләгән вазыйфа яки
структурадагы вазыйфа)
___________________________________
(бүлекчә, яшәү урыны буенча адрес)
___________________________________
(телефон номеры)

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә,
яисә идарәнең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт алу өчен

ГАРИЗА

Миңа идарә итүдә катнашырга, яисә идарәнең коллегиаль органы составына керергә (кирәклесенең астына сызарга)
________________________________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың исемен күрсәтергә)_____________________________________________________________
________________________________________________________________________________

торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, дача куллану кооперативы, күчемсез шәхси милек ияләре

ширкәте_________________________________________________________________

(түләүсез нигездә, түбәндәге

сыйфатта)________________________________________________________________

(бер генә кеше идарә итә торган идарә органы, яисә идарәнең коллегиаль органы исеме)_________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

_______________ (дата) _________________ (имза) ______________________________ (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны
тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар
белән идарә итәргә, яисә
идарәнең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү Тәртибенә

**2нче Кушымта**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә
аны яллаучыны тәкъдим итүче тарафыннан
Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында
түләүсез нигездә бер генә кеше идарә итә торган
коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итәргә,
яисә идарәнең коллегиаль органнары составына керергә
рөхсәт бирү өчен Гаризаларны теркәү

ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Ф.И.О., гариза бирүченең вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Ф.И.О., теркәүче | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |